КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 4 сентябрь г.Казань № 751

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының хезмәт ресурслары балансы фаразын эшләү турында» 2013 ел, 13 июнь, 404 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының хезмәт ресурслары балансы фаразын эшләү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының хезмәт ресурслары балансы фаразын эшләү турында» 2013 ел, 13 июнь, 404 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 22 декабрь, 970 нче; 2017 ел, 28 август, 603 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының хезмәт ресурслары балансы фаразын эшләү кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

8 нче пунктта:

8.2 нче пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8.2. Татарстан Республикасының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы – үткән ел, агымдагы ел һәм фаразлана торган чор өчен «Авыл, урман хуҗалыгы, аучылык, балык үрчетү һәм балыкчылык» икътисадый эшчәнлек төрләре буенча шөгыльләнүчеләрнең уртача еллык саны турында мәгълүматлар;»;

8.7 нче пунктчада «Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасының Спорт министрлыгы» сүзләренә алыштырырга;

8.12 нче пунктчаны төшереп калдырырга;

әлеге Кагыйдәләргә теркәлгән кушымтада:

6 нчы пунктның 2 графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«авыл, урман хуҗалыгы, аучылык, балык үрчетү һәм балыкчылык»;

13 нче пунктның 2 графасында «кунакханә» сүзен «кунакханәләр» сүзенә алыштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин